## IV ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ЧАКМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV УТЫРЫШЫ

## К А Р А Р № 9

Олы Чакмак

16 декабрь 2020 ел

### Мөслим муниципаль районы Олы Чакмак авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022-2023 еллар план чорына бюджеты турында

**Статья 1**

1. 2021 елга Олы Чакмак авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Олы Чакмак авыл җирлеге бюджетының фаразланыла торган гомуми кереме күләме 1233,1 мең сум;

2) Олы Чакмак авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 1233,1 мең сум;

3) Олы Чакмак авыл җирлеге бюджеты дефициты 0 мең сум.

2. 2022 һәм 2023 елга Олы Чакмак авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Олы Чакмак авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләме 2022 елга 1234,2 мең сум һәм 2023 елга 1238,3 мең сум;

2) Олы Чакмак авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2022 елга 1234,2 мең сум һәм 2023 елга 1238,3 мең сум;

3) 2022 елга Олы Чакмак авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 0 мең сум һәм 2023 елга 0 мең сум.

3. Олы Чакмак авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022-2023 еллар план чорына бюджет дефицитын финанслау чыганакларын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә билгеләргә.

**2 Статья**

1. 2022 елның 1 гыйнварына Олы Чакмак авыл җирлеге муниципаль эчке бурычының югары чиген 0 сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 сум күләмендә билгеләргә.

2. 2023 елның 1 гыйнварына Олы Чакмак авыл җирлеге муниципаль эчке бурычының югары чиген 0 сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 сум күләмендә билгеләргә.

3. 2024 елның 1 гыйнварына Олы Чакмак авыл җирлеге муниципаль эчке бурычының югары чиген 0 сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 сум күләмендә билгеләргә.

4. Олы Чакмак авыл җирлеге муниципаль бурычының иң югары чиге күләмен түбәндәгечә билгеләргә:

2021 елда – 0 сум;

2022 елда – 0 сум;

2023 елда – 0 сум.

5. 2021-2023 елларда Олы Чакмак авыл җирлегенең муниципаль гарантияләрен бирү планлаштырылмый.

6. 2021-2023 елларда Олы Чакмак авыл җирлегенең муниципаль эчке бурыч алулары программасы планлаштырылмый.

**3 Статья**

Олы Чакмак авыл җирлеге бюджетында 2021 елга һәм 2022-2023 еллар план чорына әлеге Карарга 2 нче кушымта нигезендә фаразлана торган керемнәр күләмен исәпкә алырга.

**4 Статья**

Олы Чакмак авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022-2023 еллар план чорына бюджет системасы бюджетлары арасында керемнәрне бүлү нормативларын әлеге Карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга

**5 Статья**

1. Олы Чакмак авыл җирлеге бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлеген әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендә расларга.

2. Олы Чакмак авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының Баш администраторлары исемлеген әлеге карарның 5 нче кушымтасы нигезендә расларга.

**6 Статья**

1. Бюджет ассигнованиеләрен 2021 елга һәм 2022-2023 еллар план чорына бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә расларга.

2. Олы Чакмак авыл җирлеге чыгымнарының ведомство структурасын 2021 елга һәм 2022-2023 еллар план чорына әлеге Карарның 7 нче кушымтасы нигезендә расларга.

**7 Статья**

Олы Чакмак авыл җирлеге Башкарма комитеты 2021 елда 2022-2023 елларда муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

**8 Статья**

1. Олы Чакмак авыл җирлеге бюджетын үтәгәндә бюджет турындагы карар белән расланган керемнәрнең гомуми күләменнән тыш фактта алынган керемнәр, агымдагы финанс елына һәм план чорына бюджет турындагы карарга үзгәрешләр кертмичә, муниципаль бурычларны түләүгә, шулай ук аларны үтәү өчен Россия Федерациясе Бюджет Кодексының 217 статьясындагы 3 пунктында каралган күләмдә бюджет ассигнованиеләре җитмәгән очракта, муниципаль берәмлекнең гавами норматив йөкләмәләрен үтәүгә юнәлдерелергә мөмкин.

2. Максатчан билгеләнештәге субсидияләр, субвенцияләр, башка бюджетара трансфертлар, шул исәптән бюджетны үтәгәндә керемнәр бюджеты турындагы карар белән расланган керемнәрдән тыш фактта аларның агымдагы финанс елы башына файдаланылмаган калдыклары,агымдагы финанс елына һәм план чорына бюджет турындагы карарга үзгәрешләр кертмичә, җыелма бюджет язмасына үзгәрешләр кертеп, бюджет чыгымнарын арттыруга: максатчан билгеләнештәге субсидияләр,

субвенцияләр, башка бюджетара трансфертлар бирүгә җибәрелә.

**9 Статья**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләр нигезендә Олы Чакмак авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыра.

**10 Статья**

Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Мөслим муниципаль районы**

**Олы Чакмак авыл җирлеге Башлыгы** **И.М.Габидуллин**